| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>СТАРОДРОЖЖАНОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ИСКЕ ЧҮПРӘЛЕ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** с. Старое Дрожжаное **КАРАР**

17.03.2025 ел № 57/1

"Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында»карар проекты турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Уставының 32 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә, Татар транспорт прокуратурасының 25.02.2025 ел №23/1-2-2025 протестын, Чүпрәле районы прокуратурасының 06.03.2025ел № 02-08-02-2025 протестын исәпкә алып Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карар проектын беренче укылышта кабул итәргә.
2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә (алга таба – текст буенчакагыйдәләр), Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советының 14.09.2017 ел, № 27/1 карары (Советның 2018 елның 22.03.2018ел № 38/1, 29.10.2021 ел, №14/2, 05.04.2022 ел №19/2, 03.10.2022ел № 24/1 карарлары белән расланган үзгәрешләр белән), кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге Уставы нигезендә халыкка җиткерергә.
4. Карар проекты буенча гавами тыңлауларны 2025 елның 18 апрелендә 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Чүпрәле районы, Иске Чүпрәле авылы, Үзәк урамы, 9 йорт.

Гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлегендә гавами тыңлауларын (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Татарстан Республикасы

Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советының 2021 елның 17 июнендәге 11/2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталында Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырылган Нигезләмә нигезендә уздырыла.

5. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча муниципаль хокукый акт проекты буенча искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алу Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советының карары белән расланган Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырылган Тәртип нигезендә үткәрелә.

6. Әлеге проект буенча гражданнарның искәрмәләре һәм тәкъдимнәре 2025 нче елның 17 апреленә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: РТ, Чүпрәле районы, Иске Чүпрәле авылы, Үзәк урамы, 11 нче йорт.

7. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советының Законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясе утырышында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советы депутатларының төзәтмәләрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, карар проектына карата гражданнар тәкъдимнәрен өйрәнергә, карар проектын эшләп бетерергә һәм аны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советына карауга кертергә тиеш

8. Әлеге карар, гамәлдәге законнарда билгеләнгән башка срокларда үз көченә кергән нигезләмәләрдән тыш, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми халыкка хәбәр итү һәм урнаштыру көнендә үз көченә керә.

Иске Чүпрәле авыл җирлеге
Башлыгы Урынбасары: Р.Д.Низамов

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Иске Чүпрәле авыл җирлеге
Советының 17.03.2025 ел
№57/1 карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр

1) **35 пунктның 35.11 пунктчасында** «тимер юллар,» сүзләрен төшереп калдырырга.;

2) **37 пунктның 5 пунктчасында** «һәм тимер юл " сүзләрен төшереп калдырырга;

3) **65, 66, 67 пунктларда** «(тимер юл)» сүзен төшереп калдырырга.

4) **185 пунктны** төшереп калдырырга.

Иске Чүпрәле авыл җирлеге
Башлыгы Урынбасары: Р.Д.Низамов